МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.04.2016 ел Казан ш. № 74/2-пр

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 29 апрелендә теркәлде, № 3346

“2015-2017 елларга Татарстан Республикасында яңа эшли башлаган фермерларга ярдәм итү” ведомство программасын раслау турында” 17 март, 2015 ел, № 50/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28 февраль, 2012 ел, № 166 карарын тормышка ашыру турында” 22 март, 2012 ел, № 197 Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгын үтәү йөзеннән, “Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы арасында төзелә торган Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында” 25 гыйнвар, 2016 ел, № 2/17-с Килешү нигезендә һәм “Россельхозбанк” ААҖнең Татарстандагы төбәк филиалындагы, “Агрокредитсоюз” Татарстан Республикасы авыл кредит куллану кооперативлары берлегендәге, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгындагы кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. “2015-2017 елларга Татарстан Республикасында яңа эшли башлаган фермерларга ярдәм итү” ведомство программасын раслау турында” 17 март, 2015 ел, № 50/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына (26.01.2016 ел, № 5/2-пр боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкка № 1 кушымтада:

4.3 пунктның 17 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Яңа эшли башлаган фермер тарафыннан грант хисабына сатып алынган мөлкәт грант алынганнан соң 5 ел эчендә, Россия Федерациясе законы нигезендә сатыла, бүләк ителә, арендага тапшырыла, башка затларга файдалануга бирелә, алыштырыла яки пай, кертем рәвешендә кертелә алмый яисә башкача урнаштырыла алмый. Әлеге шарт яңа эшли башлаган фермерларга грант бирү буенча чараларда катнашу өчен мөһим шарт булып тора һәм, ул Министрлык белән яңа эшли башлаган фермер арасында төзелә торган килешүләрдә чагылдырылырга тиеш.”;

1.2. Боерыкка № 2 кушымтада:

1.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Яңа эшли башлаган фермер тарафыннан грант хисабына һәм (яки) ярдәм хисабына сатып алынган мөлкәт грант алынганнан соң һәм (яки) ярдәм алынганнан соң биш ел эчендә, Россия Федерациясе законы нигезендә сатыла, бүләк ителә, арендага тапшырыла, башка затларга файдалануга бирелә, алыштырыла яки пай, кертем рәвешендә кертелә алмый яисә башкача урнаштырыла алмый. Әлеге шарт яңа эшли башлаган фермерларга грантлар һәм (яки) ярдәм бирү буенча чараларда катнашу өчен мөһим шарт булып тора һәм, ул Министрлык белән яңа эшли башлаган фермер арасында төзелә торган килешүләрдә чагылдырылырга тиеш.”;

3.1 пунктның 3.1.11 пунктчасын  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1.11. Бу Нигезләмәгә № 5 кушымта нигезендәге форма буенча, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 24 июль, 2007 ел, № 209-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы таләпләргә туры китереп, яңа эшли башлаган фермерның микропредприятие параметрларына туры килүен раслаган – унбиш кешегә кадәр, хезмәткәрләрнең уртача саны турында белешмә.”;

3.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мөрәҗәгать итүчеләр өстәмә рәвештә, түбәндәге кебек, программада потенциаль катнашучы буларак фермер хуҗалыгын уңай яктан бәяләгән теләсә нинди документларны тапшыра ала:”;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.4. Конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүченең үз проектын яклау нәтиҗәләре, рекомендацияләр (экспертлар советы беркетмәсендә урын алган), тапшырылган документларга җыелма анализ буенча, шулай ук түбәндәге критерийләргә таянып, конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләрне билгели:

I. Бизнес-планның Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгының өстенлекле юнәлешләренә йөз тотып эшләнелүе:

а) сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлек, мөгезле эре терлекне симертү, ат үрчетү – 7 балл;

б) дуңгыз үрчетү, сарык үрчетү, кәҗә үрчетү – 5 балл;

в) кошчылык (кош-корт: күркә, үрдәк, тавык, каз үрчетү) – 6 балл;

г) бәрәңге үстерү – 6 балл;

д) яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта) – 6 балл;

е) бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар, терлек азыгы культуралары үстерү – 5 балл;

ж) җимеш һәм җиләк культуралары үстерү – 6 балл.

II. КФХ башлыгының милкендә яки озак сроклы арендага алынган (биш ел һәм аннан күбрәк) авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен, теркәлгән, җитештерү һәм склад биналарына ия булуы (аерым затның күчемсез милек объектларына (булган һәм хәзерге) хокуклары турында күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр нигезендә) – 3 балл.

III. КФХ башлыгының милкендә яки арендага алынган (биш ел һәм аннан күбрәк) авыл хуҗалыгы максатындагы җир кишәрлегенә ия булуы (аерым затның күчемсез милек объектларына (булган һәм хәзерге) хокуклары турында күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр нигезендә) – 3 балл.

IV. Түбәндәге критерийләрнең берсе:

а) югары яки урта махсус авыл хуҗалыгы белеме турында документның булуы – 3 балл;

б) өстәмә авыл хуҗалыгы белеме курсларын тәмамлау турында документның булуы – 1 балл;

в) мөрәҗәгать итүче тарафыннан яки уртак рәвештә кимендә өч ел дәвамында шәхси ярдәмче хуҗалык тоту – 2 балл;

г) КФХ башлыгының авыл хуҗалыгында авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча кимендә өч еллык эш стажына ия булуы – 3 балл.

V. Бизнес-проектны, мөрәҗәгать итүченең эшлекле сыйфатларын оештыру сәләтен, һөнәри осталыгын, кредит тарихын, социаль һәм бюджет җаваплылыгын бәяләү КФХ башлыгы белән әңгәмәләшкәннән соң хәл ителә, максималь бәя – балл.

Бәяләнелә торган һәр проект буенча бу пунктта күрсәтелгән критерийләр нигезендә мөрәҗәгать итүченең баллары суммасы буларак билгеләнелә торган йомгаклау баллы чыгарыла. Балларның максималь дәрәҗәдә мөмкин булган саны – 21.

Конкурс комиссиясе конкурска заявкаларын кимендә 11 балл белән бәяләнеп, иң күп балл җыйган мөрәҗәгать итүчеләргә грант бирү турында уңай карар кабул итә. Уңай карала торган заявкалар саны Конкурс комиссиясе тарафыннан, Татарстан Республикасы бюджеты средстволары һәм (яки) федераль бюджет средстволары хисабына, агымдагы елда программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре лимитларыннан

чыгып,  билгеләнә.”;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.5. Конкурс комиссиясе конкурс заявкаларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларны кабул итә:

мөрәҗәгать итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләр дип тану, аларга грант һәм (яки) ярдәм бирү;

мөрәҗәгать итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу аша үтмәгән дип тану, аларга грант һәм (яки) ярдәм бирүдән баш тарту.”;

1.3. Боерык белән расланган, крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерүгә грантлар бирү һәм (яки) яңа эшли башлаган фермерларның көнкүрешен җайга салуга бер тапкыр бирелә торган ярдәм бирү турында нигезләмәгә № 1 кушымтада:

Сигезенче абзацта “10 ел эчендә”  дигән сүзләрне “5 ел эчендә” дигән сүзләргә  алыштырырга.

1.4. Боерык белән расланган, крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерүгә грантлар бирү һәм (яки) яңа эшли башлаган фермерларның көнкүрешен җайга салуга бер тапкыр бирелә торган ярдәм бирү турында нигезләмәгә № 8 кушымтада:

3.1 пунктның 3.1.8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1.8. Грант алучы (яңа эшли башлаган фермер) тарафыннан грант хисабына сатып алынган мөлкәт грант алынганнан соң 5 ел эчендә, Россия Федерациясе законы нигезендә сатыла, бүләк ителә, арендага тапшырыла, башка затларга файдалануга бирелә, алыштырыла яки пай, кертем рәвешендә кертелә алмый яисә башкача урнаштырыла алмый.”;

1.5. Крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерүгә грантлар бирү һәм (яки) яңа эшли башлаган фермерларның көнкүрешен җайга салуга бер тапкыр бирелә торган ярдәм бирү буенча ведомствоара конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составыннан чыгарырга:

“Россельхозбанк” ААҖнең Татарстандагы төбәк филиалы директоры урынбасары Григорьев Алексей Евгеньевичны.

Конкурс комиссиясе составына кертергә:

“Татарстан Республикасы аграр яшьләр берләшмәсе” төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Заһидуллина Миләүшә Мөдәррис кызын.

1.6. КФХ үстерүгә грантлар бирү һәм (яки) яңа эшли башлаган фермерларның көнкүрешен җайга салуга бер тапкыр бирелә торган ярдәм бирү буенча гаризаларны карап тикшерү буенча экспертлар советы (алга таба – экспертлар советы) составыннан чыгарырга:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы предприятиеләрне реструклаштыру һәм агробизнесны үстерү бүлегенең  шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларын һәм кооперативларны үстерү секторы әйдәп баручы белгече Фәткуллов Илгиз Фирдүс улын;

“Агрокредитсоюз” Татарстан Республикасы авыл кредит куллану кооперативлары берлегенең башкаручы директоры Ризаева Гөлфирә Зыятдин кызын;

Горшунов Дмитрий Валерьевичның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге начальнигы урынбасары”;

Экспертлар советы составына кертергә:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы предприятиеләрне реструклаштыру һәм агробизнесны үстерү бүлегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларын һәм кооперативларны үстерү секторы әйдәп баручы белгече Гыйлаҗев Дамир Винер улын;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының азык-төлек базарын үстерү бүлеге 1 разрядлы белгече Имаметдинов Илнур Әмирҗан улын.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р.Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов